БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 04 2026 ел № 165

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» 2017 елның 15 июлендәге 496 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлектә тоту, хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган хәвеф - хәтәрдән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкны яклауны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында кушымтада бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы оешмалары житәкчеләренә Гражданнар оборонасы көчләрен булдырганда әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эшләүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Житәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
20*26* елның «*20*» *04*
*165* номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә Гражданнар оборонасы көчләре турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 декабрендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә эшләнде.

## 2. Гражданнар оборонасы көчләре

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары карары белән түбәндәге гражданнар оборонасы көчләре төзелә:

коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре);

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр.

## 3. Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары

Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары булып:

коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) өчен:

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча махсус чаралар үтәү;

хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә халык өчен куркынычлар килеп чыккан очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруны тәэмин итү;

хәвеф-хәтәр килеп чыгу нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итү;

гражданнар оборонасы өлкәсендә башка махсус чаралар;

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр өчен – гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүдә һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү барышында кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янау белән

## 4. Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру тәртибе

Гражданнар оборонасы көчләрен төзү тәртибе түбәндәгечә билгеләнә:

коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) өчен – Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән;

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр өчен – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының 2014 елның 18 декабрендәге 701номерлы боерыгы белән расланган гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр төзүнең үрнәк тәртибе.

## 5. Гражданнар оборонасы көчләрен куллану

5.1. Гражданнар оборонасы көчләрен куллану Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы җитәкчесе карары буенча Гражданнар оборонасы буенча чараларны башкару өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы нигезендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар үткәргәндә.

5.2. Гражданнар оборонасы көчләрен куллануны планлаштыру алдан ук, аларны булдыру этабында гамәлгә ашырыла.

## 6. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек халәтендә тоту

6.1. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек халәтендә тоту түбәндәгечә тәэмин ителә:

әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итәрлек дәрәҗәдә шәхси составны әзерләү;

махсус техниканы, җайланмаларны, кирәк-яракны, инструментларны һәм материалларны төзек хәлдә тоту;

оператив әзерлек (тренировкалар, өйрәнүләр) дәресләрен һәм чараларын планлаштыру һәм үткәрү.

6.2. Гражданнар оборонасы көчләренең шәхси составын әзерләү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Россия Федерациясенең гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү эшләре буенча министрлыгының идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасын әзерләү, шулай ук Россия Федерациясе халкын гражданнар оборонасы

объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча әзерләү турындагы оештыру-методик күрсәтмәләренә, гражданнар оборонасы көчләрен булдыручы оешмаларның документларына туры китереп башкарыла.

6.3. Гражданнар оборонасы көчләренең әзерлеген тикшереп тору Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла:

Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм оешмалары белән команда-штаб өйрәнүләре һәм тренировкалары;

Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр белән тактик-махсус өйрәнүләр;

Балтач муниципаль районының коткару хезмәтләре (Гражданнар оборонасы хезмәтләре) белән махсус өйрәнүләр.

7. Гражданнар оборонасы көчләре эшчәнлеген тәэмин итү

7.1. Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы көчләрен төзү, әзерләү, җиһазландыру һәм куллану чараларын финанслау, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, аларны төзүче оешмаларның финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

7.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә төзелә торган гражданнар оборонасы көчләрен җиһазландыру өчен билгеләнгән матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларны туплау, саклау һәм куллану «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасын туплау, саклау һәм файдалану турында» 2000 елның 27 апрелендәге 379 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасын булдыру турында» 2014 елның 6 февралендәге 65 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.